| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>СТАРОШАЙМУРЗИНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>ДРОЖЖАНОВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЧҮПРӘЛЕ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ИСКЕ ШӘЙМОРЗА АВЫЛ<br>ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

Иске Шәйморза

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

12 ноябрь 2024 ел № 48/4

**"Җир салымы турында" гы карарга үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 31 бүлеге нигезендә, «Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында һәм Россия Федерациясе Салым кодексының беренче өлешендәге 78 статьясының 1 пунктындагы икенче абзацының гамәлдә булуын туктатып тору хакында» 2023 елның 31 июлендәге 389-ФЗ номерлы Федераль законга таянып, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Шәйморза авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

**1.** Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Шәйморза авыл җирлеге Советының “Җир салымы турындагы” 15.11.2019 елның 53/1номерлы (13.11.2020 № 3/3, 15.11.2022 № 22/5; 23.10.2023 ел №35/1; 15.11.2023 №37/3 редакциясендәге) карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 пунктның 2 пунктчасында:**:**

икенче абзацта «(индивидуаль торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) эшкуарлык эшчәнлегендә файдаланыла торган җир кишәрлекләреннән тыш)» сүзләрен«, әлеге абзацта индивидуаль торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) эшкуарлык эшчәнлегендә файдаланыла торган җир кишәрлекләреннән һәм һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артык»;

2) өченче абзацта " һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артыграк булган әлеге абзацта күрсәтелгән җир кишәрлекләреннән тыш « сүзләрен өстәргә.».

**2.** Әлеге карарны Иске Шәйморза авыл җирлегенең мәгълүмати стендларына, Иске Шәйморза авыл җирлеге сайтына урнаштырырга, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга.

**3.** Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккан көннән үз көченә керә.

**4.** Әлеге карарның гамәлдә булуы 2023 елгы салым чоры һәм аннан соңгы салым чорлары өчен җир салымын исәпләүгә бәйле хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Татарстан Республикасы Чүпрәле
Муниципаль районы Иске Шәйморза
авыл җирлеге башлыгы: И.Д.Мөхитова